**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге составына керүче Өчмунча торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

12.11.2024 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Килдураз авыл җирлегенең Өчмунча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; Өчмунча авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024 елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 113 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 92 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 62 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге составына керүче Килдураз авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Килдураз авыл җирлегенең Өчмунча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; Өчмунча авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Өчмунча авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ З.З. Әхәтов

Килдураз авыл җирлеге
башлыгы ________________ З.З. Әхәтов